СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

22.02.2019 № 8н/2
На № __________от_______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, шулай ук муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ санлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 ел, 25 декабрь, 273-ФЗ санлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 ел, 3 декабрь, 230-ФЗ санлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 23 июнь, 460 санлы Указы, Татарстан Республиксының «Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 ел, 19 июль, 56-ЗРТ санлы Законы, Татарстан Республиксы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Президентының Указына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 22 апрель, УП-330 санлы Указы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның,

шулай ук муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында нигезнамәне 1 кушымтадагыча расларга.

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар исемлеген 2 кушымтадагыча расларга (аларга билгеләнгәндә, гражданнар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, һәм шулай ук әлеге муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы).

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында нигезнамәне раслау хакында» 2016 ел, 28 март, 5/3 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров

Совет Тукаевского муниципального района